ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 384-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова, А.Я. Славутский тарафыннан кертелгән «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 384-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1860-VI ДС

384-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов,
Л.Н. Рыбакова,
А.Я. Славутский
тарафыннан кертелә

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында»
Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына
үзгәрешләр кертү хакында»**

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта «урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга,» сүзләрен «федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә урта һөнәри белемнең уку-укыту программаларын, бакалавриат программаларын, специалитет программаларын һәм магистратура программаларын, федераль дәүләт таләпләре нигезендә аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын,» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:
«$9^1$. Аспирантурада федераль дәүләт таләпләре нигезендә фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары йомгаклау аттестациясе узган затларга фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертациянең «Фән турында һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте хакында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законга таянып билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә һәм аспирантураны тәмамлау хакында таныклык бирәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты республика законын федераль законнарга туры китерү максатында эшләнде.

«Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законның 19 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 641-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы белән «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законга дин белеме бирү оешмаларының аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын федераль дәүләт таләпләре нигезендә гамәлгә ашыру хокукын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.